РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ
БОЛЬШЕШИНАРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

422054, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Большой Шинар, ул. Кооперативная, 36
тел. (84362) 41-2-11

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОЛЫ ШЫҢАР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422054, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Олы Шыңар авылы, Кооператив урамы, 36 йорт
тел. (84362) 41-2-11

e-mail: bshin.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
13.05.2019

КАРАР
№10

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының
2017 нче елның 10 нчы ноябрендә кабул ителгән
24 нче номерлы «Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеген
төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында "
карарына үзгәрешләр кертү турында»

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы прокуратурасының 2019 нчы елның 12 нче февралендә бирелгән 02-01-20-2019 нчы номерлы хаты нигезендә һәм үткәрелгән ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советы Карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының 2017 нче елның 10нчы ноябрендә кабул ителгән 24 нчы номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеген тезекләндерү кагыйдәләрен раслау турында"гы карарына (алга таба - кагыйдәләр) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. Кагыйдәләрнең I бүлеге 6 пунктын түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

"арбороцидлар" – агач-куак чүп үсемлекләренә каршы кулланыла торган химик матдәләр;

"Сосновский балтырганы" –эре үлән үсемлек, зонтиклылар гаиләсеннән балтырган тере. Үсемлек озак төзәлә торган кечле пешерү сәләтенә ия;

"гербицидлар" – үсемлекләрне юк итү ечен кулланыла торган химик матдәләр;

1.2. Кагыйдәләрнең III бүлеге 50 пунктын түбәндәге эчтәлекле 50.14 пунктча белән тулыландырырга:

"50.14) үләннәрне даими чабу, чүп үләннәрен һәм куакларын юк итү, бигрәк тә кеше тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыручыларын, шул исәптән Сосновский балтырганын.

Сосновский балтырганын һәм башка кеше тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыручы үсемлекләрне юк итү аларның чәчәккә береләнүенә һәм чәчәк ату чорына кадәр башкарылырга тиеш.

Сосновский балтырганын һәм башка кеше тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыручы үсемлекләрне юк итү түбәндәге ысуллар белән башкарылырга мөмкин:

- Химик- үсеп чыгу учакларына гербицидлар һәм (яки) арборицидлар сиптерү;
- Механик – чабу, корыган үләннәрне җыю, тамыр системасын казып алу;
- Агротехник- туфракны эшкәртү, күпьеллык үләннәр чәчү.

1.3. Кагыйдәләрнең IV бүлеге 113.5 пунктын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

"113.5. үләннәрне даими чабу (15 см-дан биегрәк булса), махсус билгеләнгән һәм чикле кулланыштагы яшелләндерелгән территорияләрдән тыш,чүп үләннәрен һәм куакларын юк итү, бигрәк тә кеше тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыручы үсемлекләрне, шул исәптән гомумкулланылыштагы җирләрдәге Сосновский балтырганын, һәм чабылган үләнне тәүлек эчендә җыештыру"

1.4. Кагыйдәләрнең IV бүлеге 114 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 2-5 абзацлар белән тулыландырырга:

"Сосновский балтырганын һәм башка кеше тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыручы усемлекләрне юк итү аларның чәчәккә береләнүенә һәм чәчәк ату чорына кадәр башкарылырга тиеш.

Сосновский балтырганын һәм башка кеше тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыручы үсемлекләрне юк итү түбәндәге ысуллар белән башкарылырга мөмкин:

- Химик- үсеп чыгу учакларына гербицидлар һәм (яки) арборицидлар сиптерү;
- Механик – чабу, корыган үләннәрне җыю, тамыр системасын казып алу;
- Агротехник- туфракны эшкәртү, күпьеллык үләннәр чәчү."

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә, карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/shinar адресы буенча һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгы А.Г.Гарипов